КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 апрель г.Казань № 303

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 20 сентябрь, 851 нче карары белән расланган Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 20 сентябрь, 851 нче карары белән расланган Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренә, 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«14. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидия чараларын күчерү килешү нигезендә, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекләрнең финанс органнарына ачылган муниципаль берәмлекләр бюджетларының бердәм счетларына гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин